| | |
|---|---|
| СОВЕТ ШИШИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЕҢШЕҢӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 31.10. 2022ел. | № 57 |

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уставын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы маддәсе нигезендә Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кушымта нигезендә расларга.

2. Шеңшеңәр авыл җирлегенең 2011 елның 27 июнендәге 27 номерлы карары белән расланган уставын (19.03.2012ел №47; 15.12.2012 ел №67; 27.02.2014 ел №93; 15.12.2014 ел №118; 19.12.2015 ел №14; 24.12.2016 ел №40; 25.01.2018; 29.08.2018 ел №83; 21.10.2019 ел №114; 22.09.2020 ел №6 редак.) үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә дәүләт теркәве өчен Уставларны теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына җибәрергә.

4. Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгына Уставларны теркәү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан кергән көннән җиде көн эчендә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://baltasi.tatarstan.ru) һәм Шеңшеңәр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында да.

5. Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгына рәсми игълан ителгәннән соң 10 көн эчендә Уставларны теркәү өлкәсендәге федераль башкарма хакимият органының территориаль органына үзгәрешләр һәм өстәмәләр рәсми игълан ителү чыганагы һәм датасы турында белешмәләр җибәрергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Салихҗанов